ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.02.2023 Балык Бистәсе штп. № 34пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү һәм (яки) су белән тәэмин итү объектларын торгызу, агымдагы ремонтлау һәм капиталь ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү максатларында юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, шулай ук товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында" 04.09.2017 №184пи карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Субсидияләр, шул исәптән, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидия формасында грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 22.12.2022 ел, №2385 карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе районыУставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә җылылык белән тәэмин итү һәм (яки) су белән тәэмин итү объектларын торгызу, агымдагы ремонтлау һәм капиталь ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү максатларында юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, шулай ук товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидияләр бирү тәртибенә (17.08.2018 №203пи, от 04.03.2020 №38пи, от 27.05.2022 №100пи редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

4 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"субсидия алучылар чит ил юридик затлары , шул исәптән теркәлү урыны булып Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслаган Россия Федерациясендә активларны арадаш (офшор) (алга таба - офшор компанияләре) тоту өчен кулланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт яки территорияләр, шулай ук устав (туплау) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки читтән торып (өченче затлар аша) катнашуы өлеше 25 проценттан артып киткән (әгәр Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса) россия юридик затлары булырга тиеш түгел. Офшор компанияләренең россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләгәндә, акцияләре Россия Федерациясендә оештырылган сатып алуларда әйләнештә булган, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында читтән торып катнашуы, әлеге ачык акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашу аша гамәлгә ашырыла торган ачык акционерлык җәмгыятьләре капиталында (шул исәптән халыкара компания статусы белән) офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) читтән торып катнашуы исәпкә алынмый;".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.Л. Исланов